ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2 статья. **Урам сәүдәсен һәм халыкның көнкүреш ихтыяҗларына хезмәт күрсәтүне оештыру тәртибен бозу**»;

б) 1 өлешнең беренче абзацында «сәүдә иткән» сүзләреннән соң «яки халыкның көнкүреш ихтыяҗларына хезмәт күрсәткән» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $3.15^1$ статья өстәргә:

«$3.15^1$ статья. **Җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне көчләп тагу**

1. Җәмәгать урыннарында гражданнарга әйберләр сату-алу, алмашу яисә аларны башка ысул белән алу йә хезмәтләр күрсәтү максатында ялыктыргыч бәйләнеп (әлеге Кодексның 3.15 статьясында каралган очраклардан тыш), җәмәгать тәртибен бозган өчен –

кисәтү ясала яисә бер мең биш йөз сум күләмендә административ штраф салына.

2. Ел дәвамында шул ук гамәлләрне кабат кылган өчен –

өч меңнән алып биш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

3) 7.1 статьяда «3.13 – 3.15» саннарын «3.13 – $3.15^1$» саннарына алмаштырырга;

4) 8.1 статьяның 14 өлешендә «3.10 (гражданнарга карата),» сүзләреннән соң «$3.15^1$,» саннарын өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 56-ТРЗ